

Газета учащихся МОУ «Усть-Туркская СОШ»

ИСКОРКА

№19
24
февраля
2016 года

Читательский контакт: тел./факс 5-31-00 e-mail: schkolaturka@mail.ru

# Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең 110 еллык юбилеена багышлана



***1906-1944***

## Җырларым

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиндем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю-
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

***1943, 26 ноябрь, Моабит төрмәсе***

## Җырлап үткән гомер

**Муса Җәлил** Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Җәйне туган авылында үткәрә. Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта, иң беренче булып, унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла. 1922 нче елда ул Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый. 1925 елда Җәлилнең «Барабыз» исемле беренче китабы чыга. «Иптәшкә» (1929) дигән шигырь җыентыгы аның шагыйрь булып җитлегеп килүен тагын бер тапкыр раслый. Ул 1931 нче елда Мәскәү университетының әдәбият бүлеген тәмамлый. 1939 нчы елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәрге елларда шагыйрь бик күп шигырьләр, җырлар, «Хат ташучы» поэмасын, «Алтынчәч», «Илдар» исемле опера либреттоларын яза.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул үзен фронтка җибәрүләрен сорый. Аның үтенече канәгатьләндерелә. Минзәләдә хәрби-сәяси җитәкчеләр (*политруклар*) әзерләүче кыска сроклы курсларны тәмамлап, «өлкән политрук» дәрәҗәсе ала. Фронт газетасында эшли башлый. 1942 нче елның җәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре бөтен дөньяга билгеле. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны бөтен дөньяда “Моабит дәфтәрләре” исеме белән беләләр. Сугыштан соң совет шагыйре һәм язучысы Константин Симонов ярдәмендә Муса Җәлилнең шигырьләре бастырыла башлый, тәрҗемә ителә, шагыйрьнең батырлыгы бөтен илгә билгеле була.

# « Татарлар елмаеп үлделәр... »

Муса Җәлил, 1942 елда Волхов фронтында канлы сугышлар вакытында нык яраланып, аңын югалтып, фашистлар тырнагына эләгә. Аңына килеп, күзен ачканда, ул инде фашистлар кулында була.

Муса Җәлил килеп эләккән фашистлар концлагеренда хәлләр коточкыч була. Качу турында уйлап та карарга мөмкин түгел. Берничә кат әйләндереп алынган стеналар, кат – кат электр тогы җибәрелгән чәнечкеле тимер чыбыклар. Һәр почмакта, чатта бар нәрсә дә үч төбендә күренерлек вышкалар, аларда иң яхшы коралланган сакчылар. Аста да адым саен котырган этләр белән фашистлар йөреп тора. Әз генә ялгыш атласаң да, үлем көтә, котырган этләр ташлана. Монда ачлыктан, салкыннан, авырулардан көн саен йөзләгән кеше үлә. Фашистлар әсирләрне куркытып тору өчен җәзалыйлар, кыйныйлар, мәсхәрәлиләр. Аларда җиңүгә ышанычны, туган илләренә мәхәббәтне бетерергә телиләр.

Муса Җәлил, җай чыккан саен, яшеренеп, татар әсирләре алдында үзенең җиңүгә ышаныч, туган илгә мәхәббәт тулы шигырьләрен укый, көрәшкә чакыра. Әсирләрнең күзләре очкынлана, фашистларга каршы нәфрәт белән йодрыклары кысыла.

Әкренләп, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре тирәсенә фашистларга каршы көрәшү өчен яшерен оешма туплана. Аңа бик сыналган, ышанычлы кешеләрне генә алганнар. Очраклы бер генә кеше эләксә дә, бөтен эшне харап итәргә, күпме кешене үлемгә дучар итәргә мөмкин бит. Яшерен оешмага кергән һәр кеше ант иткән. “Яшерен оешмага керү белән мин явыз дошманга каршы соңгы сулышыма кадәр сугышырга, Ватаныма һәрьяклап булышырга ант итәм. Кирәк икән, Туган илем иминлеге өчен тормышымны да кызганмаска сүз бирәм. Дошман кулына эләгә калсам, нинди генә җәза – җәберләргә дучар ителсәм дә, яшерен оешма турында, дусларым турында бер сүз дә әйтмәскә ант итәм.Әгәр мин шушы тантаналы антымны бозсам, мине Туган илемнең дошманы, фашистлар ялчысы дип исәпләгез.”

Фашистлар бик мәкерле, явыз план коралар. Җәзалап һәм ач тотып, әсирләрне Ватанга хыянәт итәргә һәм үз илләренә каршы сугышырга мәҗбүр итмәкче булалар. Алар моның өчен төрле милләт әсирләрен аерым – аерым җыйнап, алардан милли легионнар төзи башлыйлар. Шул милләт халыклары телләрендә газеталар чыгарырга керешәләр, радиотапшырулар оештыралар, милли комитетлар төзиләр. Бу эшләргә әсирләрнең үзләрен тарталар. Татар – башкортларга, ирекле “Идел - Урал” дәүләте төзибез дип, сафсата коралар.

Яшерен оешма кешеләре газета редакциясенә, радиостудиясенә һәм башка күп кенә оешмаларга кереп урнашалар. Яшерен оешманың төп бурычы - Кораллы восстание әзерләү, күрше поляк һәм әрмән легионнары белән элемтә урнаштыру, бергәләп хәрәкәт итү турында сөйләшеп кую, корал табу, әсирләр арасында пропаганда алып бару. Боларның барысын да бик сак, фашистларга һәм сатлыкҗаннарга сиздермичә эшләргә кирәк. Типографиядә, машинкада җай табып, листовкалар басып, бик саклык белән тараталар. “Кызылармеец иптәшләр! Үз әтиләрегезгә, энеләрегезгә һәм сеңелләрегезгә каршы барыр өчен, фашистлар сезне, ач үлем белән куркытып, алдап, легионга языларга мәҗбүр иттеләр. Кулыгызга бирелгән шул коралны чын дошманнарыгызга борыгыз!”- диелә анда. Аңлату эшләрен үзләре оештырган музыка хор капелласы аша да алып баралар. Аның җитәкчесе – яшерен оешманы оештыручыларның берсе Гайнан Кормаш була. Концертка әсирләр күңелендә илне ярату хисләре, үз халкыбыз, мәдәниятыбыз белән горурлану хисе, әсирләрне кимсеткән, алардан көлгән фашистларга карата нәфрәт уятырлык җырлар, шигырьләр сайлап алына.

1943 ел уртасында легионның беренче батальоны Белоруссиягә патризаннарга каршы җибәрелә. Барып җиткәч, батальон солдатлары баш күтәрә, немец офицерларын үтереп, бөтен кораллары, кирәк – яраклары белән партизаннар ягына чыга. Аннан партизаннар белән бергә фашистларның зур көчләрен тар – мар итәләр. Шушы уңыштан канатларган җәлилчеләр хәрби әсирләр арасында гомуми восстание күтәрергә һәм легиончыларның аерым группаларын качарга әзерли башлый. Ә дошман беренче батальон белән булган хәлдән соң бик каты сакны көчәйтә, әсирләр арасындагы сатлыкҗаннарны яшерен оешма кешеләренең ышанычын яуларга җибәрәләр. Шундыйларның берсе - үзенең кечкенә җаны турында гына уйлаган Мәхмүт Җамалетдинов, мәкерле юллар белән җәлилчеләрнең ышанычына кереп, аларны фашистларга сата. Муса Җәлил һәм аның 10 көрәштәше кулга алына, төрмәгә ябыла.

Коточкыч җәзалаулар, сорау алулар башлана. Җәлилчеләр ахыргача нык торалар. Бар эшләгән эшне үз өсләренә алып, башка беркемнең дә исемен атамыйлар.

Шулай итеп, яшерен оешманың бик күп кешеләрен үлемнән коткарып калалар.

Төп батырлык эшләнгән була инде. Легиондагы башка батальоннарны да фашистлар туган илләренә каршы сугыштыра алмыйлар. Йә алар безнең гаскәрләр ягына чыгалар, йә фашистлар, аларның бу эшләрен сизеп, тизрәк кире Германиягә җибәрергә мәҗбүр булалар.

Җәлилчеләр үлем сәгатен озак көтәләр. Фашистлар аларны әкрен интегүле үлем белән генә түгел, рухларын сындырып үтерергә телиләр. Әмма коточкыч газапларга карамастан һәм һичшикчез үләчәкләрен белсәләр дә, җәлилчеләр көчле рухлы булып калдылар. Муса Җәлил туган илгә көрәшкә багышланган иң әйбәт һәм бик күп шигырьләрен үлем сәгатен көткәндә язды. Аның “Моабит дәфтәре” дигән шигырьләре ничә еллар, ничә куллар аша Туган иленә кайтты.

Муса Җәлилнең көрәштәшләре дә берсеннән - берсе батыр, берсеннән - берсе туган илләрен яратучы, берсеннән - берсе фашистларны ныграк күрә алмаучы кешеләр иде.

Фашистлар суды аларның башларын кисәргә хөкем итте.

Аларны фашистлар 1944 елның 25 августында, төш вакытында гильотинада җәзалап үтерделәр.

Әмма алар антларына үлгәндә дә тугры калдылар. Аларның үлеменә шаһит булган Германия рухание соңыннан: “Татарлар елмаеп үлделәр,”- дип искә төшерде. Әйе, алар фашистларны җиңеп, халкыбызның намусын саклап калып, безнең бүгенге көнебез хакына батырларча һәлак булдылар. Җәлилчеләр, үлгәннән соң, Бөек Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнделәр.

## Җәлилчеләр




**Гайнан Кормаш**
**Фоат Сәйфелмөлеков**
**Абдулла Алиш**
**Фоат Булатов**
**Гариф Шабаев**
**Әхмәт Симаев**
**Абдулла Баттал**
**Зиннәт Хәсәнов**
**Әхәт Атнашев**
**Сәлим Бохаров**



***Казан, 1 нче май мәйданында җәлилчеләргә куелган монумент***

## Муса Җәлил турында...

Г. Кашшаф, «Муса турында истәлекләр»

Үлемсезлек таңында: Муса Җәлил турында истәлекләр.

Җәлилова Х., « Абыем турында»

Мостафин Р., «Муса Җәлил эзләре буйлап»

Мостафин Р., «Өзелгән җыр эзеннән».

«Моабитская тетрадь», нәфис фильм, реж. Леонид Квинихидзе, Ленфильм, 1968.

«Красная ромашка», нәфис фильм, ДЕФА (ГДР).

Нәҗип Җиһанов, «Җәлил» операсы

Ю. Корольков, «Через сорок смертей»

Т.Миңнуллин, «Моңлы бер җыр» драмасы

Х.Якупов , «Хөкем алдыннан» картинасы



***Казан, Муса Җәлил һәйкәле***

# Муса Җәлил исеме белән...

**Музей-квартира**, Казан, ул. М. Горького, д. 17 кв. 28.

**Посёлок**, Татарстан..

**Һәйкәлләр:** Казан, Әлмәт, Минзәлә, Мәскәү , Түбән Кама, Нижневартовск, Оренбург, Яр Чаллы, Санкт-Петербург, Тосно (Ленинград өлкәсе), Челябинск.

**Опера һәм балет театры**, Казан

**Мәктәп** №1186, Мәскәү

**Проспект һәм урамнар**

**Кинотеатр**, Түбән Кама

**Библиотека**, Ижевск

**Монумент**, Казан

**Музей**, Мостафа авылы, Оренбург өлкәсе

**Татарстан Республикасы премиясе**




*М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры*





*М.Җәлилгә багышланган һәйкәлләр*

# Муса Җәлил гаиләсе













**Адрес: с.Усть-Турка, ул.Ленина, 19**
**Редактор: Кашапова Карина**
**Куратор: Нуртдинова Ч.Ф.**